БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 09 » сентябрь 2021 ел № 280

2021 елның IV кварталына Балтач муниципаль районы буенча торакның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача бәясен раслау турында

«Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру максатларында һәм «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлык тарафыннан 2021 елның 29 гыйнварындагы 23 номерлы хатында бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «2020 - 2025 елларга Балтач муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында, 2021 елның IV кварталына Балтач муниципаль районы буенча торакның гомуми мәйданының бер квадрат метрының бәясен 27173 сум 90 тиен күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов